ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2026 п.г.т. Алексеевское № 136

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.07.2021ел, № 281 «Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына 2 нче кушымтаның үз көчен югалтуын тану хакында**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТР номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карарын игътибарга алып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.07.2021 № 281 «Инфраструктура үсеше бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына 2 нче кушымтаның (Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е. Н.Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**